| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2022 елның 10 ноябре № 22/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 30 мартындагы 26/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы әгъзаларының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә

ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 30 мартындагы 26/1 номерлы (11.05.2018 № 27/3, 28.09.2020 № 1/5, 03.02.2022 № 16/1 редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **1 пунктта** «11 163,0» саннарын «11 958,00» саннарына алмаштырырга;

2) **1 нче Кушымта таблицасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**« МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАЛАРНЫ ДАИМИ НИГЕЗДӘ БИЛӘҮЧЕ ЗАТЛАРГА, МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННЫҢ КОНТРОЛЬ-ХИСАП ОРГАНЫ РӘИСЕНӘ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ ҺӘМ ШАРТЛАРЫ**

| Вазыйфаның атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 8 төркем | 10 төркем | 11 төркем | 12 төркем |
| Муниципаль район Башлыгы | 31 660,00 | | | |
| Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы урынбасары | 28 494,00 | | | |
| Контроль-хисап органы рәисе | 28 494,00 | | | |
| Авыл җирлеге башлыгы урынбасары | | 14 527,00 | | |
| Авыл җирлеге башлыгы | | | | 16 390,00»; |

**3) 2 нче Кушымта таблицасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМЕ**

| Вазыйфаның атамасы | Вазыйфаи эш хакы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Район Башкарма комитеты Җитәкчесе | 31 091,00 |
| Район Советы Аппараты җитәкчесе | 28 221,00 |
| Район Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары | 27 982,00 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе | 27 863,00 |
| Эшләр идарәчесе | 26 188,00 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 25 591,00 |
| Бүлек башлыгы | 21 764,00 |
| Район башлыгы киңәшчесе | 19 013,00 |
| Район башлыгы ярдәмчесе | 19 013,00 |
| Район Башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе | 19 013,00 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 19 013,00 |
| Сектор мөдире | 17 578.00 |
| Баш белгеч | 16 861,00 |
| Әйдәп баручы белгеч | 15 665,00 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 11 958,00»; |

4) **3 нче Кушымта таблицасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМЕ**

| | Вазыйфаларның исеме | Хезмәт хакы | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 10 төркем | 11 төркем | 12 төркем |
| 1. | Башкарма комитет Җитәкчесе | 19 492,00 | | |
| 2. | Башкарма комитет секретаре | | | 15 905,00». |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы урынбасары, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе урынбасары: А.Е. Ярухин